Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение

«Усть-Туркская средняя общеобразовательная школа»

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор МАОУ «Усть-Туркская СОШ» |
| ______/Муртазина | ______/ Аитова Э.Р. | ______/ Юсупова И.Ф. |
| Протокол №1 от «30» августа 2024 г. | «30» августа 2024 г. | Приказ №123 от «30» августа 2024 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**учебного предмета «Родная (татарская) литература»**

для обучающихся 11 класса

**с. Усть-Турка 2024**

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Сүз сәнгате булган әдәбият – тормышны үзенчәлекле танып белү формасы, ул хисси-эмоциональ тәэсир чаралары ярдәмендә дөнья сурәтен, моделен төзү һәм шуңа карата мөнәсәбәт формалаштыру сәләтенә ия. Мәктәптә укыту предметы буларак ул әхлакый-эстетик һәм интеллектуаль әзерлекле шәхес, гражданин тәрбияләүдә турыдан туры катнаша. Укучы әдәби әсәрләр, аларның авторлары фикере аша гомумкешелек кыйммәтләрен, халыкның рухи байлыгын үзләштерә - тормыш фәлсәфәсенә төшенә. Шуңа күрә гомуми белем бирү системасында бу укыту предметының әһәмияте зур.

XXI гасырның беренче чирегендә гомуми белем сыйфатына таләпләрнең үзгәрүенә, яңа карашлар формалашуга нисбәтле, укытуның эчтәлеген заманга туры китереп яңарту, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү, методик алым-чараларны камилләштерү, әдәбият укытуны яңа нигезләргә кору көн тәртибенә куелды. Татар әдәбияты тарихындагы, әдәбият белемендәге яңарыш-үзгәрешләр дә, татар әдәбиятыннан үзләштерелергә тиешле белемнәргә таләпләр дә уку-укыту эчтәлеген яңарту кирәклекне искәртә.

Урта белем бирү мәктәпләре (X-XI сыйныфлар) өчен татар әдәбияты предметыннан тәкъдим ителә торган үрнәк программа шушыларны исәпкә алып төзелде. Ул Россия Федерациясендәге һәм Татарстан Республикасындагы мәгарифкә кагылышлы хокукый-норматив актларга һәм икенче буын федераль дәүләт мәгариф стандартларына нигезләнде. Алга таба татар әдәбияты предметыннан төп (авторлык) һәм эш программаларын төзү өчен нигез булып торачак: монда укыту предметының мәҗбүри өлеше билгеләнгән. Үрнәк программада гомуми төп белем бирү баскычында (V-IX сыйныфлар) формалаштырыла башлаган барлык күнекмәләрне үстерү күздә тотыла.

Программа югары сыйныфларда һәр баланың татар әдәбиятыннан яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, укучыларны әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән таныштыруны,

татар әдәбиятының барышы, милли әдәбиятның күпгасырлык тарихы һәм аның аерым чорларына хас үзенчәлекләр хакында белем бирүне күздә тота; чор әдәбиятының үзенчәлекләрен һәм зур сүз осталары иҗатының яңалыгын дөрес аңларга, объектив нәтиҗәләр ясарга, мөнәсәбәт формалаштырырга юнәлеш бирә, балаларның психик һәм физик сәламәтлеген саклауны тәэмин итә.

Урта белем бирә торган мәктәпләрдә татар әдәбияты предметы укучыларга әдәби белем бирүне, әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын аңлау өчен кирәкле иҗади һәм теоретик күнекмәләр формалаштыруны, милли мәдәниятләргә кагылышлы мәгълүматлар җиткерүне үз өченә ала.

Югары сыйныфларда әдәбият укытуның төп **максатын** исә татар әдәбиятының барышын, аның аерым чорлардагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү тәшкил итә. Әлеге максатка түбәндәге **бурычлар** аша  ирешелә:

- укучыларда татар әдәбиятының тарихи барышы турында гомуми караш булдыру;
- әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының, гомумән татар әдәбиятының үзенчәлекләрен табарга, аңларга, бәяләргә күнектерү;
- иҗади фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне танырга өйрәтү;
- матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау, укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләрен тәрбияләү;
- заман таләпләренә җавап бирүче, үз-үзен камилләштерү өстендә даими эшләүче, татар әдәбиятын, мәдәниятен, традицияләрен хөрмәт итүче, татар дөньясына, әдәбиятына кагылышлы бәхәсләрдә катнашып, үз фикерен дәлилли алучы, гуманлы, рухи, әхлакый бай шәхес тәрбияләү.

## УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урта белем бирүче мәктәпләрдә татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда әдәбиятны аңлау күнекмәсе булдырыла, әхлакый позиция һәм эстетик зәвык тәрбияләнә, иҗади фикерләү үстерелә, һәм болар дөньяга карашны, тормышны бәяләү чарасына әверелергә тиеш.

Югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **гомуми (метапредмет) нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәбиятны үзе иҗат ителгән чор контекстында аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну ихтыяҗы тәрбияләү;
- сүз сәнгатен халыкның мәдәни үсеш билгесе буларак кабул итәргә өйрәтү, аның шәхесне рухи баету мөмкинлекләрен төшендерү;
- укучының язу һәм сөйләм, мөстәкыйль иҗади фикерләү һәм бәяләү осталыгын үстерү;
- укучыны үз холык-фигылен, эш-гамәлләрен контрольдә тотарга, үз рухи дөньясын баету өстендә эшләргә өйрәтү;
- әдәби-мәдәни мәгълүматлар алу өчен төрле чыганаклардан файдаланырга күнектерү.

Югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- аерым чорларда иҗат ителгән әсәрләрне форма һәм эчтәлек берлеге төсендә кабул итәргә өйрәтү, сайлап уку ихтыяҗы булдыру һәм әсәргә салынган мәңгелек кыйммәтләрне билгеләргә күнектерү;
- укыган әдәби әсәрнең үзе иҗат ителгән чор белән тарихи-мәдәни бәйләнешләрен аңлавына ирешү;
- укучының классик әдипләр тормыш һәм иҗат юлын, милли әдәби барышның төп этапларына хас үзенчәлекләрне һәм билгеләрне белүе;

- рефератлар, докладлар  әзерләргә, әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинениеләр язарга, иҗади эшләр башкарырга өйрәтү;
- әдәбият тарихын тикшергән вакытта әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

*бәяләү өлкәсендә*:

- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- милли әдәбиятка, андагы күренешләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя формалаштыру, әсәргә, язучы иҗатына, чор әдәбиятына бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерергә өйрәтү;
- өйрәнелгән әсәрләрне чор әдәбияты фонында шәрехли белүенә ирешү;
- автор осталыгын бәяли алу һәм аңа карата мөнәсәбәт формалаштыру.

*эстетик яктан*:

- сүз сәнгатенең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, эстетик зәвык формалаштыру;
- төрле мәдәни дөньяларның, милли әдәбиятларның казанышларына игътибарлы һәм ихтирамлы караш тәрбияләү.

Югары сыйныфлар  зур тормышка аяк басарга әзерләнүче бала өчен мөһим этап булып тора, аның шәхес буларак формалашып җитү, тирә-юньгә, башкаларга мөнәсәбәте калыплашу, дөньяга үз карашы ныгу чорын тәшкил итә.  Шуңа күрә **шәхси нәтиҗәләр** арасында түбәндәгеләре аерым әһәмияткә ия:

- укучының  гражданлык позициясен, акыл һәм рухи эшчәнлеген, иҗтимагый бурыч хисен активлаштыру;
- алган белем һәм  күнекмәләрен тормышта куллана белергә, үз юлын сайларга әзерләү, мөстәкыйль карарлар кабул итәргә күнектерү;

- жәмгыятьтә башкаларны, аларның үзгә фикер-карашын, мәдәниятен, традицияләрен хөрмәт итеп яшәргә өйрәтү;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак нормаларын, жәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- мәктәпне тәмамлап чыккач та матур әдәбият укуга ихтыяҗ, әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, поэтикасын аңларлык эстетик зәвык булдыру.

Югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предметара нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыларда әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалаштыру;
- татар теленә бәйләнештә, туган телдә аралашырга ихтыяҗ һәм аңа хөрмәт тәрбияләү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты белән бәйләп, тема һәм проблематикада, геройлар бирелешендә, иҗат юнәлешләрендә, чор әдәбиятларында уртаклыкларга игътибар итү.

## ӘДӘБИЯТ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Өлкән сыйныфлардагы әдәбият курсы сүз сәнгатенең тарихи үсешен системалы күзаллау булдыруга һәм шуның аша классик һәм хәзерге әдәбиятның үзара бәйләнешен тулырак аңлауга юнәлтелә.

Тәкъдим ителә торган материал татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш этапларына бәйле рәвештә бүлеп бирелә. Әдәби әсәрләр хронологик тәртиптә урнаштырыла, аерым очракларда укытучы, билгеле бер максаттан чыгып, аларның урынын үзгәртә ала. Укучыларның белем һәм яшь үзенчәлекләренә бәйле әсәрләрнең күләме арту һәм әдәби процесс үзгәреше белән бәйләнештә бирелүе әдәби материалның катлаулана баруына китерә.

Югары сыйныфларда татар әдәбияты үрнәкләрен анализлау әдәбият тарихына карата бөтенлекле күзаллау булдыруда катнаша. Әдәби үрнәкләр өч максатка юнәлтелә: аерым әдәби әсәрләр уку һәм анализлау, аерым берләре укып фикер алышу, кайберләре сыйныфтан тыш уку өчен тәкъдим ителә. Әмма һәр очракта да алда куелган критерий һәм таләпләр истә тотыла.

### Әдәбият тарихы

**Борынгы татар әдәбияты (5—12 гас.)**

Гомумтөрки әдәбият. Орхон–Енисей ташъязмалары.

**Урта гасыр әдәбияты**

Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятындагы өч юнәлеш (дини-дидактик, яңарыш һәм суфичылык). Милли сүз сәнгатенең шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Аллаһның берлеген раслаучы дини һәм гадел идарәче, гуманлы шәхесне алга куйган дөньяви мотивларның кушылуы. Әхлакый камил, гадел, гуманлы, сабыр, изге күңелле, эчке һәм тышкы матурлыкка ия шәхес концепциясе. Жанрлар төрлелеге, шәркый жанрларның кулланылыш үзенчәлекләре.

**Болгар чоры мәдәнияте** (12–13 гас. 1 яртысы). Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы.

**Алтын Урда чоры мәдәнияте** (13–15 гас. 1 яртысы). С.Сараиның «Гөлестан бит төрки» поэмасы. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы.

**Казан ханлыгы чоры мәдәнияте** (15 гас.1 яртысы–16 гас.2 яртысы). Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр иҗаты.

**Торгынлык чоры мәдәнияте** (16 гас.2 яртысы–19 гас.I яртысы*)*. М.Колый  хикмәтләре. Г.У. Имәни иҗаты.

**Яңарыш чоры әдәбияты**

XIX гасырның беренче яртысы әдәбияты. Г.Кандалый, Акмулла иҗатлары.

XIX гасырның икенче яртысы әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте. Әдәбият мәйданына реализмның килүе, мәгърифәтчелек реализмы, аңа хас төп сыйфатлар, мәгърифәтчелек идеалларының гәүдәләнеше. Әдәби әсәр үзәгендәге гади җир кешесенең милләт язмышы белән үрелеп сурәтләнүе. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Дөньяви һәм дини мотивларның бирелешендә яңалыклар. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.

**XX йөз башы мәдәнияте**. XX гасыр башында сүз сәнгатенең үсеш-күтәрелеш чорын кичерүе. Шушы чорда иҗтимагый-сәяси тормышта барган үзгәрешләр, аларның иҗтимагый-сәяси һәм әдәби фикергә йогынтысы, шәрык һәм гареб (көнбатыш) синтезы. Әдәбиятның тормышны реалистик һәм романтик чагылдыру үзенчәлекләре. Заман героена хас сыйфатлар, гыйсъянчы, ялгыз, урталыктагы, үзен милләткә багышлаган яки төшенкелектәге һ.б. төр геройлар. Язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр.

Реализмның мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализм баскычына күтәрелүе. Сүз сәнгатенең иҗат юнәлешләре, агымнары ягыннан баюы. Модернистик агымнардан импрессионизм, символизм. Милли мәсьәләләрнең активлашуы. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. Рухи азатлык, иман, гомернең чиклелеге, яшәү һәм үлем, матурлык проблемаларын яңача хәл итү омтылышы.

Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Камал, Ф.Әмирхан, М. Фәйзи, Г.Колахмәтов иҗаты.

**1920-1930 елларда** әдәбиятның каршылыклы үсеше. Романтизм, модернизм (символизм, имажинизм, футуризм һ.б.) иҗат юнәлешләренең әдәби мәйданнан төшерелеп, социалистик реализм агымының төп иҗат методы буларак раслануы. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр.

М.Галәү, К.Тинчурин, Г.Рәхим, Һ.Такташ иҗаты.

**Сугыш чоры мәдәнияте**. Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Еники, Ф.Хөсни иҗаты.

**Сугыштан соңгы чор мәдәнияте** (1950–1960 еллар). XX гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. Х.Туфан, Х.Вахит иҗаты.

**1960–80 еллар мәдәнияте.** Татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой. «Авыл прозасы». Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Романтизм юнәлешенең

яңадан тергезелүе. 1917 еллар инкыйлабына, яңадан төзелгән тормышка бәянең үзгәреш кичерүе. Сугыш темасының үзгә яссылыкта куелышы.

Ә.Еники, С.Хәким, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, М.Мәһдиев иҗаты.

**1980–2000 еллар мәдәнияте.** XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Үзгәрешләрнең XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булуы. Реализмның типиклаштыруны иҗтимагый–сыйнфый баскычтан гомумкешелек югарылыгына күтәрүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу.

И.Салахов, Ф.Бәйрәмова, М.Хәбибуллин, Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Г.Афзал, Р.Фәйзуллин, М.Әгъләмов, Зөлфәт иҗаты.

**2000—2010 еллар мәдәнияте.** Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау. Кешенең аңында, аң төпкелендә барган процессларны тергезү. Мифологик, шартлы–символик образларның активлашуы ярдәмендә милли проблематиканы яңа яссылыкта кую, миллилекне тоталитар идеологиягә каршы торучы көч итеп күтәрү.

М.Кәбиров, З.Хәким, Р.Зәйдулла иҗаты.

Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.

## Әдәбият теориясе

**Әдәби төр һәм жанрлар.** Эпос, лирика һәм драма төрләре. Эпик жанрлар: роман, повесть, хикәя. Эпик жанрларның төрләре: тарихи роман (повесть яки хикәя), көнкүреш романы, производство романы, психологик роман, маҗаралы, детектив роман. Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Шәрык әдәбиятларында лирик жанрлар: мәдхия, мәрсия, газәл касыйдә, робагый. Драма жанрлары: комедия, трагедия, драма. Драма жанрларының төрләре:

моңсу комедия, тарихи драма, психологик драма. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма. Поэма жанрының төрләре: романтик поэма, реалистик поэма. Төрара формалар: сәяхәтнамә.

**Әдәби әсәрдәге образлылык.** Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Лирик герой, хикәяләүче, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе.  Табигать образы, әйбер образы, мифологик образ, фантастик образ, архетип.

**Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма.** Автор, укучы (адресат). Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Мотив, лейтмотив. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. Текст: эпиграф, багышлау, көчле позиция.

**Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль.** Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Лирик чигенешләр. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа. Шигырь төзелеше. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар. Чор стиле.

**Әдәбият тарихы.** Традицияләр, яңачалык. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият. Әдәби бәйләнешләр: тәэсир, назыйрә, пародия.

**Әдәби барыш.** Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты; иҗат юнәлешләре (реализм, романтизм); суфичылык, мәгърифәтчелек, модернизм, постмодернизм күренешләре; иҗат методы (агымы): мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, социалистик реализм, авыл реализмы, символизм, гыйсъянчылык, импрессионизм, имажинизм, футуризм.

## Күнекмәләр формалаштыру

Укучыга билгеле бер күләмдә белем бирү белән янәшә, аларны ныгыту, күнекмә дәрәҗәсендә беркетү кирәк була. Әдәбият шикелле белемнәр анализлау-тикшерү барышында үзләштерелә торган предмет өчен бу аерата мөһим. **Күнекмәләр булдыру** эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдә үстерелә һәм бәяләнә:

- **рецептив эшчәнлек**: сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты, чор әдәбияты турында чагыштырып, бәяләп, яттан өзекләр китереп сөйләү; әдәби әсәрнең төрен, жанрын, язучы иҗатының төп хасиятләрен, чор әдәбиятының төп үсеш юнәлешләрен билгеләү һәм фикерне исбатлау; әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау; әдәби әсәрләрнең тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, әдәбияттагы «үтәли» һәм «мәңгелек» проблемаларны ачыклый алу.

- **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, башка әсәрләр белән чагыштыра, бәяли алу; чор әдәбиятына кагылышлы мәгълүматларны гомумиләштереп сөйли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.

- **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; әдәби әсәрләр, язучы иҗаты, чор әдәбияты, гомумән милли әдәбият буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу;

- **эзләнү эшчәнлеге**: әдәби әсәргә, язучы иҗатына, чор әдәбиятына, милли әдәбияттагы аерым күренешләргә нисбәтле проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әсәр белән башка текстлар, шул исәптән башка сәнгать төрләре арасында ассоциатив бәйләнешләрне күрә алу;

- **тикшеренү эшчәнлеге**: тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү; татар, рус (яки башка халыкларның) әдәбиятларында бер төрдәге темага язылган әсәрләрне чагыштыру, милли үзенчәлекләрен ачыклау; татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты мәйданындагы урынын һәм ролен бәяләргә омтылу.

## УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМЕНӘ, ЭШ ОСТАЛЫГЫНА ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕНӘ ТАЛӘПЛӘР

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:

- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларын һәм аларның әсәрләре хакында;
- милли әдәбиятның нинди чорларга бүленешен;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- әдәби-тарихи барышның төп закончалыкларын һәм әдәби юнәлеш, күренешләрнең төп сыйфатларын;
- төр әдәби-теоретик төшенчәләрне

**белергә**;

- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият тарихыннан һәм теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының аерым якларын, элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын иҗтимагый-тарихи контекстта һәм гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында бәяләү;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын, кайсы чорда язылуын билгеләү, чор әдәбиятына хас сыйфатларны табу;
- бер чорда иҗат ителгән һәм төрле чорларда иҗат ителгән әдәби әсәрләрне чагыштыру;
- әдәби әсәргә карата дәлилле шәхсән мөнәсәбәт белдерә алу;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару

**күнекмәләрен** үзләштергән булырга тиеш.

## УКЫТУНЫ МАТДИ-ТЕХНИК ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ

Укытуның матди-техник яктан тәэмин ителеше белем бирүнең сыйфаты белән турыдан-туры бәйләнгән һәм түбәндәге яссылыкларда аеруча игътибар үзәгендә булырга тиеш:

- уку-укыту бинасының һәм кабинетларның төзеклеге, эстетик бизәлешнең укучы зәвыген һәм милли үзаңын, этномәдәни күзаллавын үстерерлек булу;
- укытучы эшчәнлеген дөрес оештыру, дәрестән тыш, тәрбия чаралары, мәдәни чаралар (язучыларның юбилейларына, күренекле даталарга багышлап кичәләр, язучылар һәм галимнәр белән очрашулар, иҗади-музыкаль кичәләр, спектакльләр кую, әсәрләрне сәхнәләштерү, яшь иҗатчылар, сәнгатьле уку конкурслары) уздыруга зур игътибар бирү;
- мәктәп һәм кабинетның заманча җиһазландырылуы, кабинетта рәсем һәм сынлы сәнгать әсәрләренә репродукцияләр, музыкаль әсәрләр; дәресләрдә куллану өчен таратма һәм күрсәтмә әсбаплар, методик һәм мәгълүмати материалларның җитәрлек күләмдә булуы;
- дәресләрдә файдалану өчен, китапханәдә тиешле санда китаплар, дәреслекләр, белешмә әдәбият булдыру, халык авыз иҗаты үрнәкләре тупланган җыентыклар, тарихи чыганаклар, сүзлекләр, энциклопедияләр; балалар өчен чыгарыла торган газета һәм журналлар, яңа әдәби китаплар белән даими тәэмин итү;
- лингафон кабинет булдыру, укытучыны техник, телевидение һәм Интернет мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итү өчен кирәкле чаралар, шул исәптән аудио-һәм видеоәсбаплар, мультимедиа укыту программалары, электрон дәреслекләр һәм ярдәмлекләр, электрон китапханә, укучыларның белемнәрен тикшерү өчен компьютер программалары белән тәэмин итү;
- сәләтле укучылар өчен газета-журналларда, фәнни җыентыкларда мәкаләләр бастыру, конкурсларда, тематик-гамәли конференцияләрдә, семинарларда катнашу өчен шартлар тудыру.

**Гомуми урта (тулы) белем бирү**

**мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә**

**торган әсәрләр минимумы**

**XI сыйныф**

М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» циклы.

Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» повесте.

Х.Туфанның «Иртә төшкән кар» шигырьләре.

Мәхмүт Хәсәнов.”Язгы аҗаган”

Мөсәгыйт Хәбибуллин. “Кубрат хан”

М.Мәһдиев. “Бәхилләшү”

А.Гыйләҗев. “Йәгез, бер дога!”

И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» драмасы

Рәдиф Гаташ. ”Укытучы”

Ренат Харис. “Сабантуй”

Р.Фәйзуллин. «Нюанслар илендә» циклы.

Мөдәррис Әгъләм, “Тиз эрүдәмени?..”Мөхәммәт Мирза, “Тыңла...”.

Зөлфәт. “Колын”, “Дүрт җыр”, “Тылсым”.

Разил Валиев.”Сөембикә”, “Минем гомер”, “Дустым”, “Үзгәрергә!”

Туфан Миңнуллин.”Әлдермештән Әлмәндәр”

Н.Гыйматдинованың «Киләчәк » повесте**.**

Ркаил Зәйдулла.Битлек”, “Саташкан кыш”.

Зөлфәт Хәкимнең “Телсез күке”

**Дәреслек**

Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 11 нче сыйныф. Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ф.Җамалиева. – Казан: «Мәгариф - Вакыт» нәшр.,2019.- 439 б.: рәс. б-н.

**Календарь-тематик план**
**11 нче сыйныф**

| Дәрес № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1. | Бөек Ватан сугышы чорына гомуми күзәтү | 1 | | |
| 2. | М.Җәлил иҗаты.Р.Зәйдулла, "Җәлил кояшы". Р.Фәйзуллин "Үлмәс җыр"" | 1 | | |
| 3. | 1950-1960нчы еллар әдәбиятына хас үзенчәлекләр. XX гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. Әдәбият теориясе. Диалогия . | 1 | | |
| 4. | Х.Туфанның тоткынлык чор иҗатында моң-зар, хәсрәт-сагыну, фаҗига хисләренең яңа төсмерләр алуы. “Сиңа”, “Лу-и-за-а-а...”, “Агыла да болыт агыла”, “Кайсыгызның кулы җылы?”шигырьләре. | 1 | | |
| 5. | Х.Туфанга багышланган әсәрләр.С.Гәрәева, “Хәсән Туфанга”, И.Юзеев, “Хәсән Туфан фатихасы” шигырьләре, уку, анализлау.Х.Туфанның татар шигырь төзелешенә алып килгән яңалыгы. Әдәбият теориясе. Туфан строфасы. | 1 | | |
| 6. | Х.Туфанга багышланган әсәрләр.С.Гәрәева, “Хәсән Туфанга”, И.Юзеев, “Хәсән Туфан фатихасы” шигырьләре, уку, анализлау.Х.Туфанның татар шигырь төзелешенә алып килгән яңалыгы. Әдәбият теориясе. Туфан строфасы | 1 | | |
| 7. | Гариф Ахунов. “Хәзинә”романы. Әдәбият теориясе. Конфликт төшечәсе. | 1 | | |
| 8. | 1960–90нчы еллар әдәбияты.Проза. | 1 | | |
| 9. | Мәхмүт Хәсәновның тормыш юлы, иҗаты. Язучыга багышланга әсәрләр | 1 | | |
| 10. | Мәхмүт Хәсәнов..”Язгы аҗаган” романы | 1 | | |
| 11. | Мөсәгыйт Хәбибуллинның тормыш | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | һәм иҗат юлы.. “Кубрат хан” романы.Тарихи роман төшенчәсе. | | | |
| 12. | М.Мәһдиевнең тормыш юлы, иҗаты. Язучыга багышланга әсәрләр “Бәхилләшү” әсәре. | 1 | | |
| 13. | М.Мәһдиевнең “Бәхилләшү” әсәре.Реализм. Крестьян реализмы | 1 | | |
| 14. | Аяз Гыйләҗев иҗатына күзәтү. Язучыга багышланган әсәрләр. Әдәбият теориясе. Документаль әдәбият. | 1 | | |
| 15. | А.Гыйләҗев, “Йәгез, бер дога!” | 1 | | |
| 16. | 1960–90нчы еллар татар поэзиясе. Әдәбият теориясе.Сонет.Шигъри роман. | 1 | | |
| 17. | Илдар Юзеев иҗатына күзәтү. Язучыга багышланган әсәрләр | 1 | | |
| 18. | Илдар Юзеев, “Гашыйклар тавы” | 1 | | |
| 19. | Рәдиф Гаташ иҗатына күзәтү. Әдипкә багышланган әсәрләр. ”Укытучы” | 1 | | |
| 20. | Ренат Харис иҗатына күзәтү. Әдипкә багышланган әсәрләр. “Сабантуй” | 1 | | |
| 21. | Ренат Харис. “Сабантуй” | | | |
| 22. | Равил Фәйзуллин иҗатына күзәтү. Язучыга багышланган әсәрләр. | 1 | | |
| 23. | Мөдәррис Әгъләм, “Тиз эрүдәмени?..”Мөхәммәт Мирза, “Тыңла...”. Әдәбият теориясе.Лирика жанрлары. | 1 | | |
| 24. | Зөлфәт иҗатына күзәтү. “Колын”, “Дүрт җыр”, “Тылсым”. | 1 | | |
| 25. | Разил Валиев иҗатына күзәтү.”Сөембикә”, “Минем гомер”, “Дустым”, “Үзгәрергә!” | 1 | | |
| 26. | 1960–90нчы еллар татар драматургиясе. Әдәбият теориясе.Трагокомедия. | 1 | | |
| 27. | Туфан Миңнуллинның тормыш юлы, иҗаты. Язучыга багышланган әсәрләр. Татар театр сәнгатен үстерүдә Т.Миңнуллин драматургиясенең роле.”Әлдермештән Әлмәндәр” | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28. | Туфан Миңнуллин.”Әлдермештән Әлмәндәр” | 1 | | |
| 29. | Чорга гомуми күзәтү. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау. Кешенең аңында, аң төпкелендә барган процессларны тергезү. Мифологик, шартлы–символик образларның активлашуы ярдәмендә милли проблематиканы яңа яссылыкта кую, миллилекне тоталитар идеологиягә каршы торучы көч итеп күтәрү. Нәбирә Гыйматдинованың тормыш юлы, иҗаты. | 1 | | |
| 30. | Нәбирә Гыйматдинова. “Киләчәк”. Әдәбият теориясе.Магик реализм. | 1 | | |
| 31. | Ркаил Зәйдулланның тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү.”Битлек”, “Саташкан кыш” | 1 | | |
| 32. | Зөлфәт Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү. Язучыга багышланган әсәрләр. “Телсез күке” | 1 | | |
| 33. | Зөлфәт Хәкимнең “Телсез күке” әсәренең идея-проблематикасы, образлар системасы.. | 1 | | |
| 34. | Тестларга нәтиҗә ясау. Татар әдәбияты узган юл. | 1 | | |